Тәрбия

# Гыйлем иясе һәм дин терәге - Риза хәзрәт Фәхретдин



Ризаэтдин Фәхретдин «бала тәрбияләүне бишектән башларга кирәк», дип саный. Ул ана буласы хатын-кызның үзен тәрбияләү мәсьәләләренә дә бик зур игътибар бирә. Мәсәлән, ул:

«Бала тәрбияләү ананың гаиләдәге генә түгел, ә бөтен җәмгыять алдындагы изге һәм җаваплы бурычы булып тора», - дип искәртә.

Халык педагогикасы һәм аның нигезен тәшкил иткән тәрбия, әдәп, әхлак мәсьәләләре кешелек җәмгыятенең гаилә белән яши башлавы барлыкка килгәннән соң формалаша, камилләшә бара. Кеше гаилә һәм җәмгыять берлегендә тормыш тәҗрибәсе туплый һәм өзлексез чарлана. Халык педагогикасы һәрвакыт чистарылып, идеаль тәрбия чарасына әверелеп, халкыбызның рухи сафлыгы үрнәге һәм мәңгелек йөз суы, йөз аклыгы булып тора...

Риза Фәхретдин балаларны дөрес тәрбияләү ата-аналарның изге бурычы икәнен ассызыклап әйтә. Моның белән бергә бу җаваплы гамәлнең җәмәгатьчелек эше икәнен дә кат-кат искәртә. Мәшһүр галимебез үзенең 1917 елда Оренбургта басылган «Җәвамигуль-кәлим шәрхе» исемле китабында болай дип яза:

“Тәрбияле изге балалар күктән төшмиләр, бәлки, гаиләләр эчләрендә җитешәләр. Балаларга яшь вакытларыннан башлап яхшы тәрбия бирү — ата-ана өстендәге иң олуг бурычтыр”...

Чын мәгънәсендәге татар зыялысы булган Ризаэтдин Фәхретдин, гасырлар дәвамында яшәп килгән бер бик зур бәхәскә дә ачыклык кертеп, аны озайтмаслык итеп нокта куя. Ул да булса — дин һәм сәнгать арасындагы үзара мөнәсәбәт турындагы бәхәс. Сәнгатьнең кеше әхлагын тәрбияләүдә нинди мөһим чара булганлыгын һәм дин белән сәнгатьнең бер-берсенә капма-каршы булмауларын «Җәвамигуль-кәлим шәрхе»ндә җентекләп аңлатып яза.

Ризаэтдин Фәхретдин дин һәм сәнгатьнең үзара мөнәсәбәтләренең адәм баласы өчен бернинди дә зыяны булмавын, ә, киресенчә, бик зур файдасы барлыгын дәлилли. Аның фикеренчә, кешенең аң дәрәҗәсе үскән һәм тәҗрибәсе арткан саен, тәрбия чаралары да үскән, арткан, камилләшкән һәм билгеле бер кануннар җыелмасы рәвешенә кергән. Ислам дине кабул ителгәнче үк, әлеге кануннар иң яхшы әхлакый һәм рухи тәрбия чараларын үз эченә алганнар. Алар татар халкы үзе булдырган, үзе иҗат иткән бөек бер ядкәр булганнар һәм, Ислам дине кабул ителгәч, аларга дини төсмерләр дә бирелеп, тагын да камилләшкәннәр.

Гөнаһ, әдәп һәм башка төшенчәләр белән тулыландырып, аларны тагын да баетканнар. Ислам дине алып килгән рухый һәм әхлакый тәрбия ысуллары белән каршылыкка килмәгәннәр, киресенчә, камилләштерелгәннәр. Нәкъ менә шушы халыкчан һәм дини тәңгәллекләргә нигезләнеп, Ризаэтдин Фәхретдин үзенең «Болгар вә Казан төрекләре» исемле китабында Ислам диненең борынгы Болгар дәүләтендә бернинди каршылыкларсыз таралып, үсеп чәчәк атуын һәм рәсми дәүләт дине итеп кабул ителүенең сәбәбен аңлатып бирә. Ул: «Болгар иленә Ислам дине каршылыксыз килеп керде һәм уңай гына таралды, чөнки ул аларның рухи халәтләренә яраклы һәм туры килә торган иде», — дип яза. Димәк, безнең борынгы бабаларыбыз үз Ватаннарына Ислам дине килгәнче үк, ул таләп иткән әхлакый һәм рухи тәрбия кысаларында яшәгәннәр.

Хатыннарның һәм ирләрнең вазыйфаларына, сыйфатларына, нинди булырга һәм ни белән шөгыльләнергә тиешлекләренә дә ул бик тәфсилләп туктала.

Никахлашыр өчен иң әүвәл ике яктан да мәхәббәт, яратышу, аннан соң теләк, омтылыш, холык һәм табигатьләренең туры килүе, яшь аермасы зур булмау, бер-берсенә тиң булу кирәклеген дә яхшылап аңлата. «Үзе теләмәгән һәм яратмаган егеткә кызны бирү — зур гөнаһ.

Моңа һичкемнең хакы юк!» — дип кисәтеп куя ул.

Киләчәк саннарда да без бөек педагог, дин, тарих һәм башка фәннәр буенча галим булган Риза хәзрәт Фәхретдиннең гыйльми үгет-нәсыйхәтләрен бастырачакбыз.

*Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.*

# Балаларга үгет-нәсыйхәт

1. И, газиз балалар! Ата-аналарыгыз сезне тәрбияләп үстерү өчен авыр һәм мәшәкатьле хезмәт итәләр. Алар һәрвакыт сезнең өчен тырышалар. Аллаһы Тәгаләгә ялварып, сезнең иминлегегез өчен догалар кылалар. Инде сез дә аларның бу яхшылыкларын һәм бу хезмәтләрен камил кылып, үзләренә дә кайтарыгыз. Көчегездән килгәнчә, аларга чын күңелдән хезмәт итегез һәм хөрмәт күрсәтегез! Бу - Аллаһы Тәгаләнең боерыгы! Мөхәммәт (с.г.с.) бу хакта: «Ата-аналарын риза кылучы балалардан Аллаһы Тәгалә дә риза булыр», — диде.

2. Ата-аналарыгыз киләчәктә сезнең хөрмәтле һәм файдалы булуыгызны өмет итеп, Аллаһы Тәгаләдән ялварып сорыйлар. Инде сез дә мондый изгелекләргә каршы явызлык кылучылар булмагыз. Аларның үгет-нәсыйхәтләрен куркып һәм өркеп түгел, бәлки, яратып кабул итегез. Чөнки алар күп тәҗрибә аркылы бу дөнья хәлен һәм аның серләрен сездән күбрәк беләләр.

3. Кешенең итагатьле булуы - аның күңеле яхшы һәм саф булуында. Сезгә иң якын кешеләрегез - алар ата-аналарыгыз. Шуның өчен аларга һәрвакыт итагатьле булыгыз, эштә һәм сүздә аларга каршы килмәгез. Шул вакытта аларның күңелләре дә һәм үзегезнең күңелләрегез дә рәхәт табар, тормышыгыз уңышлы һәм гүзәл булыр.

4. Ата-аналарыгыз алдында әдәпле булыгыз, аларның сүзләрен яхшы тыңлагыз. Алар белән кычкырмый гына, әдәп белән, ачык итеп сөйләшегез. Алар аяк өстендә торганда сез утырып тормагыз.

5. Батырлык — ул адәм балаларындагы хөрмәтле бер сыйфат. Олылар мәҗлесендә булып, алардан хикмәтле сүзләр ишетү акылны арттыра һәм гыйлемлекне күбәйтә. Шуның өчен, йөрәксез балалар кебек, ата-аналарыгыз белән киңәшеп утырудан курыкмагыз һәм белмәгән, аңламаган нәрсәләрегезне сораудан тартынмагыз.

6. Йөргән вакытыгызда әти-әниегез очраса, аларга һәм аның белән бергә булганнарга сәлам биреп, хезмәтләрен үтәргә әзер торыгыз! Әгәр утырып торган вакытыгызда килсәләр, ачык йөз белән урыныгыздан торып каршылагыз!

7. Ата-аналарыгыз сезгә нәрсә бирсәләр дә, үзләренең миһербанлыклары белән бирерләр. Шуның өчен нәрсә сорасагыз да, башкалар юк вакытта әдәп белән сорагыз. Әгәр сораган нәрсәгезне бирмәсәләр, аларны борчымагыз. Сезгә нәрсә кирәк һәм нәрсә кирәк түгел икәнлеген һәм сезгә нинди эшләр туры килү-килмәвен алар сездән артыграк беләләр.

8. Атагызның иң якын дустыннан булса да, атагыз рөхсәтеннән башка нәрсә дә булса сорау гаеп эш һәм гаилә хөрмәтен җибәрүдер. Шуның өчен йомышларыгызны башкалардан түгел, ә атагыздан сорагыз.

9. Бала чагында акча тотарга өйрәнмәгән кешеләр олы булгач та аны белмиләр һәм бөтен байлыкларын исраф итеп, дөнья рәхәтен күрмиләр. Шуның өчен ата-анагыз биргән акчаларны тота белергә өйрәнегез. «Бу аз гына акча» димәгез, чөнки әлегә сезнең кирәкләрегез дә аз.

10. Кайбер балалар аталарының малларына ышанып, һичбер кәсеп һәм эш юлына кермичә, ялкаулыкка гадәтләнеп китәләр. Нәтиҗәдә акчалары да бетә, тереклек итәр өчен кулда һөнәрләре дә булмый. Шуның өчен ата малына ышанып тормыйча, нинди зур бай баласы булсагыз да, үзегезне ярлы кеше баласына санап, һөнәргә өйрәнергә тырышыгыз.

11. Дөньяда шатлыкларны һәм кайгыларны уртаклашыр өчен якын һәм ышанычлы кешеләр кирәк. Балалар өчен әти-әниләре - иң ышанычлы кешеләр. Алар баланың шатлыгы өчен үзеннән дә артыграк сөенәләр, ә кайгыхәсрәтләрен җиңеләйтү өчен кулларыннан килгән чараларның бөтенесен эшләргә тырышалар. Шуның өчен бар булган серләрегезне аларга гына сөйләгез, алар һәрвакыт ата-аналарыгызның күңелләре булсын.

12. Күзгә күренгән һәрбер нәрсәгә кызыгучы булмагыз. Аналарыгызның кунаклар өчен әзерләп куйган нәрсәләренә тимәгез. Рөхсәтсез әйбер алырга өйрәнгән балалар ахырда угры булалар.

13. Тәнегезгә көч кергәч, кулыгыздан килгән эшләрдә ата-аналарыгызга ярдәм итегез. Алар сезне кечкенәдән тәрбияләп үстерделәр.

14. Бер көнне сез дә әти, әни булырсыз, шунда сезне дә балаларыгыз хөрмәтләр.

Рәсүлебез Мөхәммәд галәйһиссәләм: «Ата-аналарыгызга игелек итегез, сезгә дә балаларыгыз игелек итәр», — диде.

16. Ата-аналарының тәрбияләре һәм мәшәкатьләре күләгәсендә рәхәт күреп үскән кайбер балалар соңыннан аларның фикерләренә каршы киләләр, хәтта сүзләрен дә ишетергә теләмиләр. Бернәрсә дә белмисез, дип алардан көләләр. Сез дә шундый инсафсыз балалар булмагыз.

17. Тиешсез бер эш кушсалар һич тартынмыйча һәм шул ук вакытта күңелләрен рәнҗетмичә генә, инсаф белән, ул эшнең тиешсез икәнлеген аңлатырга тырышыгыз.

*Риза ФӘХРЕТДИННЕҢ*
*«Нәсыйхәт» китабыннан.*

# Җеннәр кеше йортларында яшиме?

Сәад бин Әбү Вәккас (р.г.) әйтте: «Бервакыт минем яныма бер кеше килде, аны минем хатыным өйгә тизрәк кайтсын дигән үтенеч белән җибәргән. Мин өйгә кайткач, ул әйтте: «Кара бу еланга, мин аны бервакыт сәхрәдә күрдем, күзләреннән аны таныдым». Шуннан соң Сәад Аллаһыга мактау әйтеп, еланга мөрәҗәгать итте: «Чынлап, син безгә начарлык китерәсең. Аллаһы белән ант итәмен, әгәр дә мин сине яңадан күрсәм, үтерәчәкмен». Елан йорттан ишек аша чыгып китте.

Ибн Гакыл сөйләде: «Багдад шәһәрендә бер йорт булган. Анда кешеләр кунарга туктаган вакытта иртәнгә бөтенесе дә үле булалар. Бервакыт монда Коръән хафиз (яисә Коръәнне яттан белүче кеше) туктады һәм ошбу йортның күршеләре иртән аның исән-сау икәнлеген күргәч, гаҗәпләнделәр һәм аңардан төнне ничек үткәрдең, дип сорадылар. Ул җавап кайтарды: «Мин кичен намаз укыдым һәм Коръән укый башладым, кинәт ишек алдында урнашкан коедан җен күтәрелде һәм мине сәламләде. Мин курыктым. Ә ул әйтте: «Миннән курыкма, ә Коръәннән берәр нәрсә өйрәт». Минем куркуым юкка чыкты һәм аңардан сорадым: «Ошбу йортта нәрсә булды?» Ул җавап бирде: «Без, мөселман җеннәр, намаз һәм Коръән укыйбыз. Ә бу йортта гел азган кешеләр туктыйлар иде. Алар җыелышып, хәрәм эчемлекләр эчәләр иде. Без аларны буа идек». Мин аңа: «Төнлә синнән куркам, көндез кил», — дидем. «Ярый», — диде ул һәм көндез күтәрелде дә, без аның белән дусларча сөйләштек».

Кайчагында кешеләр юри өйдә җеннәр бар дип уйлап чыгаралар. Шәех Ясин Әхмәд сөйләде: «Бер шәһәрдә бер зиннәтле өйнең хуҗасы үлгәч, аның йортын сату турындагы хәбәр тирәюньгә таралгач, шәһәрдә ошбу йортта Гыйфрит (җеннәрнең башлыгы) яши дигән имеш-мимеш таралды. Кешеләр бу йорттан читләшәләр иде. Нәтиҗәдә варислар йортны сата алмабыз дип курка башладылар. Шул вакытта йортны күпләтә азрак хакка алырга ризалашкан кеше килде. Варислар ризалашканда гына бер кыю егет килде һәм Гыйфритны йорттан куып чыгарам, дип вәгъдә бирде. Варислар аның белән килештеләр.

Теге егет кичен ошбу йортка кереп, шәмне сүндереп, йокларга ятты. Төн уртасында кемнеңдер кулы аның юрганын тартканын сизде. Ул бөтен көче белән аңа тотынып: «Кем минем юрганымны тарта?», - дип сорады. «Бу мин — Гыйфрит, бир миңа юрганыңны яисә мин синең тәнеңә паралич суктырырмын», - дип әйтте. Егет юрганын җибәрде һәм Гыйффрит аны үзенә тарткан вакытта, егет сикереп торды да Гыйфриткә ташланды. Өстенә менеп утырды һәм сорады: «Кем син?» Тегесе нык курыккан тавыш белән җавап бирде: «Мин Гыйфрит түгел, ә синең кебек үк кеше, ләкин кара тәнле». Егет аны җибәрде дә шәмне кабызды. Ул кара тәнле, ярымшәрә колны күрде һәм: «Син бу йортта нишләп йөрисең?», — дип сорады. «Мин ярлы кеше, минем зур гаиләм бар, аны миннән башка асраучы юк. Бер кеше миңа акча өчен ошбу йортка төн саен килеп, монда кунган кешеләрне куркытырга тәкъдим итте. Һәм кешеләр монда кунганда мин төрле шаулар чыгарып, куркыныч тавыш белән кычкырып, аларны куркыта идем». Егет моны ишеткәннән соң, колны варислар янына алып барып, аларга тапшырды һәм шушы хикәяне сөйләде. Теге кеше ошбу йортка яман дан чыгарып бик арзанга йортны сатып алмакчы булган».

*Вәлиулла хәзрәт ЯГЪКУБ.*